КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 07 октябрь г.Казань № 1260

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Предприятиеләрдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган инвалидларның эш урыннарын саклауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюдетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы; 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы; 2021 ел, 12 февраль, 73 нче; 2022 ел, 20 июнь, 591 нче; 2022 ел, 24 ноябрь, 1260 нчы; 2023 ел, 10 февраль, 127 нче, 2023 ел, 1 июнь, 667 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклау белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемдә «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктта «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

1.2 пунктта «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктта:

беренче абзацта «төзелгән» сүзен «шул исәптән төзелгән» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «ачыкланган» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) арасыннан эш бирүчеләр;»;

өченче абзацта «50 процент» сүзләрен «30 процент» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2.1 пунктның унөченче абзацында «оешмалар,» сүзеннән соң «шул исәптән» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин